ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 105-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 105-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 385-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8-9; 2016, № 1-2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш);2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 18 пунктны өстәргә:

«18) техник – гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре – махсус икътисадый зоналар төзү турындагы килешүләрне гамәлгә ашыру максатларында булдырылган һәм идарәче компания балансында төп чаралар объекты буларак санала торган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтне исәпкә куйган айдан соң килә торган айдан башлап ун ел узгач, мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән;»;

б) $3^1$ өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 3 пунктны өстәргә:

«3) техник – гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре – махсус икътисадый зоналар төзү турындагы килешүләрне гамәлгә ашыру максатларында булдырылган һәм идарәче компания балансында төп чаралар объекты буларак санала торган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтне исәпкә

куйган айдан соң килә торган айдан башлап ун ел узгач, мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән.»;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 14,15 пунктларны өстәргә:

«14) 2029 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 18 пунктын;

15) 2032 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы $3^1$ өлешенең 3 пунктын».».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасыннан һәм 2 пунктының өченче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасы һәм 2 пунктының өченче абзацы 2029 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 18 пункты нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2025 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

Россия Федерациясе Салым кодексының 381 статьясындагы 23 пункт нигезендә махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре тарафыннан таныла торган һәм балансларында төп чаралар объектлары буларак исәпкә алучы, махсус икътисадый зоналар төзү турындагы килешүләрне гамәлгә ашыру максатларында төзелгән күчемсез милек булган оешмалар әлеге мөлкәтне исәпкә кую аеннан соң килә торган айдан соң ун ел дәвамында салым салудан азат ителәләр.

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясы нигезендә оешмалар мөлкәтенә салым төбәк салымнарына кертелгән. Россия Федерациясе Салым кодексының 372 статьясындагы 2 пунктына туры китереп салым билгеләнгәндә Россия Федерациясе субъектлары законнары белән шулай ук салым ташламалары, салым түләүчеләр тарафыннан аларны куллану нигезләре һәм тәртибе каралырга мөмкин.

Федераль дәрәҗәдә билгеләнгән ташламаның гамәлдә булу вакытын озайту максатларында закон проекты белән техник - гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре өчен махсус икътисадый зоналар төзү турындагы килешүләрне гамәлгә ашыру максатларында төзелгән, баланста төп чаралар объектлары буларак исәпкә алына торган мөлкәткә карата салым ташламалары суммасын, күрсәтелгән мөлкәтне исәпкә кую аеннан соң килә торган айдан ун ел узгач, атап әйткәндә:

2025 - 2028 елларда исәпләнгән салым суммасының 4,55 проценты күләмендә, 2029 - 2031 елларда исәпләнгән салым суммасының 50 проценты күләмендә билгеләү тәкъдим ителә.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Техник - гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре өчен махсус икътисадый зоналар төзү турындагы килешүләрне гамәлгә ашыру максатларында төзелгән, баланста төп чаралар объектлары буларак исәпкә алына торган мөлкәткә карата салым ташламалары суммасы, күрсәтелгән мөлкәтне исәпкә кую аеннан соң килә торган айдан ун ел узгач, түбәндәге күләмдә бәяләнә:

2025 - 2028 елларга 97,4 млн сум,

2029 - 2031 елларга 40,2 млн сум.